**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«10» октябрь, 2019 ел — Кече Шилнә авылы — № 6/2

Кече Шилнә авыл җирлегендә җирле референдум үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләре, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20, 35 маддәләре, «Җирле референдум турында» 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 маддәсе, Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 10 октябрендәге 45 номерлы карары, Кече Шилнә авыл җирлеге Советының 2019 елның 10 октябрендәге 6/1 номерлы карары, Кече Шилнә авыл җирлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2019 елның 1 декабренә якшәмбе көнгә Кече Шилнә авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитеты белән берлектә Кече Шилнә авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турында инициативаны чыгарырга, җирле референдум сорауларын түбәндәгечә формалаштырырга:

«2020 елда яшәү урыны буенча Кече Шилнә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, I, II төркем инвалидлар һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан тыш, 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Кече Шилнә, Олы Шилнә, Ильбухтино, Белоус авылларында, Ильичевка һәм Опушка поселокларында юлларны ремонтлау;
- Ильичевка поселогында, Олы Шилнә, Ильбухтино, Кече Шилнә авылларында урам яктырткычларын ремонтлау һәм урнаштыру;
- Олы Шилнә авылында янгын гидрантларын урнаштыру;
- Кече Шилнә авылында футбол кыры һәм хоккей корты төзелеше;
- Олы Шилнә һәм Кече Шилнә авылларында тукталыш павильонын төзекләндерү;
- Олы Шилнә, Кече Шилнә, Ильбухтино, Белоус авылларында һәм Опушка поселогында балалар-спорт мәйданчыгын төзекләндерү;
- Олы Шилнә һәм Кече Шилнә авылларында ясалма юл тигезсезлекләрен урнаштыру;
- Олы Шилнә һәм Кече Шилнә авылларында суүткәргеч челтәрен төзекләндерү (скважиналар бораулау);

- Олы Шилнә һәм Кече Шилнә авылларында тротуарларны төзекләндерү».

3. Референдумны әзерләү һәм үткәрүне референдум комиссияләренә йөкләргә:

- муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә (Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясе);

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләре.

4. Җирле референдум үткәрү белән бәйле чыгымнарны Кече Шилнә авыл җирлеге бюджеты средстволары хисабына гамәлгә ашырырга.

5. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырырга.

6. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмати стендларында һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы, А.Г. Даутов
Совет рәисе